Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлегенең Түбән Колчура авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2019 елның 26 ноябре 2№

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 19 номерлы Әлки муниципаль районының «Югары Колчура авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 окябрендәге 18 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе»карары, 2019 елның 26 ноябрендәге 3 номерлы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлегенең Түбән Колчура авылында гражданнар җыены йомгаклау беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге составына керүче Түбән Колчура авылындагы гражданнар җыенын узган, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

**2.** «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчурино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
алардан:

*1) урамнарны яктыртуга кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтаж эшләре һәм урам утлары кулланылган электр энергиясе өчен түләү-60 сум.*
*2) суэтем башнясы территориясен койма белән әйләндереп алу, реконструкция ясау, су белән тәэмин итү объектларын карап тотуга чыгымнарга, урамны су белән тәэмин итү системасын ремонтлауга һәм санитар-химик һәм бактериологик анализларга түләүгә-185 сум*
*3) юлларны төзекләндерү – 170 сум.*
*4)зиратларны реконструкцияләү, төзекләндерү һәм карап тоту-100 сум.*

*5) каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм утильләштерү һәм контейнер мәйданчыклары төзү өчен– 85 сум.* мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

**3.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчурино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада укучы студентлардан кала, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
алардан:

*1) урамнарны яктыртуга кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтаж эшләре һәм урам утлары кулланылган электр энергиясе өчен түләү-60 сум.*
*2) суэтем башнясы территориясен койма белән әйләндереп алу, реконструкция ясау, су белән тәэмин итү объектларын карап тоту чыгымнарына, урам су белән тәэмин итү системасын ремонтлауга һәм санитар-химик һәм бактериологик анализларга түләүгә-185 сум*
*3) юлларны төзекләндерү - 170 сум.*
*4)зиратларны реконструкцияләү, төзекләндерү һәм карап тоту-100 сум.*
*5) каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм утильләштерү һәм контейнер мәйданчыклары төзү өчен– 85 сум.*

4.Халык җыены нәтиҗәләрен Югары Колчура авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Югары Колчура авыл җирлеге башлыгы: Е. В. Краснова